РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 апрель 2025 ел № 6-77

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының даими нигездә эшләүче сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа район Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының даими нигездә эшләүче сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2008 елның 29 февралендәге 7-25 номерлы карарына ( 04.02.2011 № 5-6, 31.07.2012 № 13-21, 31.08.2012 № 8-22, 09.11.2012 № 7-25, 17.10.2013 № 10-35, 15.09.2017 № 16-24, 24.04.2018 № 10-31, 12.11.2020 № 9-3, 21.10.2022 №5-35, 14.02.2023 №5-40, 28.06.2024 №6-62, 23.01.2025 №7-72 Буа район Советы карарлары редакциясендә) (алга таба текст буенча - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгына айлык акчалата бүләкләүне 42 778 сум күләмендә һәм айлык акчалата түләүне 175 967 сум күләмендә билгеләргә.»;

1.2. карарның 2 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башлыгы урынбасарына айлык акчалата бүләкләүне 38 498 сум күләмендә һәм айлык акчалата түләүне 81 812 сум күләмендә билгеләргә.»;

1.3. карарның 4 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ рәисенә айлык акчалата бүләкләүне 38 498 сум күләмендә һәм айлык акчалата түләүне 81 812 сум күләмендә билгеләргә.».

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatrstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов